Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
Башкарма комитеты
карары

№10009
25.09.2026

«Яшьләр сәламәт яшәү рәвеше яклы»
шәһәр акциясе үткәрү турында

Яр Чаллы шәһәре халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау һәм наркотизацияләүне профилактикалау эшен оештыру максатында, Башкарма комитетның «2026-2028 елларга Яр Чаллы шәһәрендә халыкны наркотизацияләүне профилактикалау» муниципаль программасы турында» 2025 елның 21 октябрендәге 8534 номерлы Карарын үтәү йөзеннән, шәһәр Уставының 41 статьясы нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсенә «Яшьләр сәламәт яшәү рәвеше яклы» шәһәр акциясен 2026 елның 12 октябреннән 2026 елның 30 ноябренә кадәр үткәрергә.

2. Расларга:

1) «Яшьләр сәламәт яшәү рәвеше яклы» шәһәр акциясен үткәрү турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) «Яшьләр сәламәт яшәү рәвеше яклы» шәһәр акциясен үткәрү буенча оештыру комитеты составын, 2 нче кушымтада каралганча.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2026 елның 25 сентябрендәге
10009 номерлы карарына
1 нче кушымта

«Яшьләр сәламәт яшәү рәвеше яклы»
шәһәр акциясен үткәрү турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. «Яшьләр сәламәт яшәү рәвеше яклы» шәһәр акциясе (алга таба – акция) яшьләр тарафыннан наркотик чаралар кулланууны кисәтү, яшьләрдә тормышның уңай кыйммәтләрен, үз-үзеңне тотуның һәм шәхси ресурсларның югары функцияле стратегияләрен формалаштыруга юнәлдерелгән комплексы профилактик чараларны гамәлгә ашыру максатыннан үткәрелә.

2. Әлеге нигезләмәдә каралган чараларны Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе, Башкарма комитетның мәдәният идарәсе, Башкарма комитетның район хакимиятләре гамәлгә ашыра.

2 бүлек. Акциянең формалары һәм чаралары

3. Акция түбәндәге формаларда гамәлгә ашырыла:

1) Интернет, кәрәзле телефон һәм ышаныч телефоны аша наркотикларның таралу урыннары турында мәгълүмат тапшыру юлы белән гражданнарны профилактик активлыкка тарту;

2) шәһәр оешмаларында профилактик программаларны гамәлгә кертү;

3) яшүсмерләр һәм яшьләр өчен психологик семинарлар, интерактив чаралар;

4) наркомания проблемалары буенча ата-аналар лекторийлары;

5) иҗтимагый берләшмәләр вәкилләре белән очрашулар;

6) яшүсмерләр һәм яшьләр өчен профилактик интерактив видеолекцияләр, дәресләр, уеннар, тренинглар;

7) тематик фестивальләр, күргәзмәләр, ток-шоулар, матбугат конференцияләре;

8) спорт ярышлары, спартакиадалар, уеннар.

4. Акция кысаларында түбәндәге чаралар гамәлгә ашырыла:

1) массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүмати-реклама чаралары:

- белгечләрнең аналитик мәкаләләре;

- әлеге тематика буенча белгечләрнең рекомендацияләре һәм консультацияләре;

- шәһәр халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау буенча җирле үзидарә органнарының, коммерцияле булмаган иҗтимагый оешмаларның эшчәнлеген яктырту;

- сәламәтлек саклау мәсьәләләре буенча балигъ булмаганнар арасында мәгълүмати-агарту эше;

- мәгариф оешмаларының наркоманияне профилактикалау эшчәнлеге турында мәгълүмат тарату;

- балаларны, яшүсмерләрне һәм яшьләрне массакүләм спорт һәм ял эшчәнлегенә җәлеп итү;

- белгечләрне (шәһәрнең Мактаулы гражданнарын, педагогларны, психологларны, социологларны, медицина хезмәткәрләрен, балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчә инспекторларын, шәһәрнең иҗтимагый оешмалары вәкилләрен, дин әһелләрен) наркотизацияләү проблемалары буенча яшьләр телерадиопрограммаларында катнашуга җәлеп итү;

- массакүләм мәгълүмат чаралары өчен тематик материаллар тәкъдим итү;

- халыкның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту проблемалары буенча мәгълүмати буклетлар, аудио- һәм видеопродукцияләр, социаль реклама тарату;

2) яшәү урыны буенча:

- спорт ярышлары уздыру;

- массакүләм мәдәни чаралар уздыру;

- гаилә ялын оештырырга ярдәм итү;

- «хәвеф төркеме» яшүсмерләре җыела торган урыннарда профилактик рейдлар үткәрү;

3) консультация-укыту:

- гаилә консультациясе;

- мәгълүмат линияләренең эше;

- белем бирү оешмаларында, яшьләр сәясәте оешмаларында психологик ярдәм консультация пунктлары эше;

- наркотикларга бәйлелектән терелеп килүчеләрне реабилитацияләү, бәйлелектәгеләргә консультацияләр бирү буенча үзара ярдәм төркемнәре;

- сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау буенча иреклелеләр хәрәкәтләре оештыру һәм аларның эше.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева